СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Зеленодольск №358

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 128 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 149 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 8 ноябрендәге «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 259-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы,2007 елның 8 ноябрендәге «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 128 номерлы карары (2022 елның 24 мартындагы 149 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Башкарма комитет автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының исемлеген

билгели һәм (яисә) автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирә.

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән муниципаль учреждениеләр үз вазыйфаларына автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кергән вазыйфаи затларны билгелиләр.

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль Башкарма комитеты исеменнән вазыйфаи затлар гамәлгә ашыра, аларның вазыйфаи бурычларына әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яки вазыйфаи инструкция нигезендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль төрләре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү керә (алга таба шулай ук - автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар).

Автомобиль транспортында муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга ия булалар һәм җавап тоталар .

Башкарма комитет җитәкчесе контроль чараны уздыру турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи зат булып тора(алга таба - Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты).»

1.2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 128 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 149 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәнең «Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеге» 2 нче кушымтасын, әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы Рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2023 елның 28 декабрендәге
358 номерлы карарына
1 нче кушымта

« Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2021 елның 17 декабрендәге
128 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу рискы индикаторлары исемлеге**

Зеленодольск шәһәре территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне бозу рискын күрсәтүче индикаторлар:

1. Муниципаль контроль объектында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында торак пункт чикләрендә һәм (яки) җирле әһәмияттәге бер үк юлда утыз көн календарь көн эчендә ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте булуы.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, контрольдә булган зат йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел эчендә, алдагы календарь ел белән чагыштырганда, даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир өсте, электр транспорты белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларының биш процентка һәм аннан да күбрәккә артуы.

3. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан бирелгән белешмәләр нигезендә бер календарь елы эчендә , алдагы календарь елы белән чагыштырганда, юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санының ике һәм аннан да күбрәк тапкыр артуы.

4. Контрольдә тотылучы затның милкендә яки файдалануында булган юл участогында юл транспорт һәлакәтләренең ( өч бозудан да кимрәк булмаган) календарь аена, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, кимендә биш процентка артуы.

5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында, яки юл һәм урамнар киселешендә, канәгатьләнерлек булмаган юл шартларына бәйле рәвештә , кешеләр зыян күргән яки җәрәхәт алган, бер төрдәге юл-транспорт һәлакәтенең өч һәм аннан да күбрәк килеп чыгу факты ачыклануы.»